**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕНӘЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«30» июль, 2019 ел Татарстан совхозы поселогы № 107

Тукай муниципаль районы Кенәз авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннарны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 маддәсе 8 өлеше һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» 2019 елның 10 июлендәге 67/516 санлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Кенәз авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Кенәз авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

– Татарстан совхозы поселогы , С.Поповы урамы, 4-енче өй, мәгълүмат стенды;

– Татарстан совхозы поселогы , Совет урамы, 8,13-енче өй, мәгълүмат стенды;

– Татарстан совхозы поселогы , Мәктеп урамы, 6-енче өй, мәгълүмат стенды;

– Татарстан совхозы поселогы , 50 ел Октябрь урамы, 4-енче өй, мәгълүмат стенды;

— Сосновый Бор поселогы ФАП, В.Максимов урамы, 2-енче өй, Нагорный урамы. 1-енче өй мәгълүмат стенды;

- Казиле авылы ФАП мәгълүмат стенды ;

– Чершелы авылы мәдәният йорты

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Т.И.Белова